ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

«Югары Ослан муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләренә һәм белгечләренә, баш бухгалтерларга һәм бухгалтерларга (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм аның шартлары турында» Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 23.04.2019 ел №394 карары белән расланган (Башкарма комитетның 28.10.2020 №1002, 25.10.2022 №1269, 10.01.2023 №20, 08.05.2024 №543, 26.10.2024 №1364, 08.04.2025 №465 карарлары редакциясендә) авыл җирлекләренең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ һәм «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ, «Югары Ослан муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм аның шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында.

Югары Ослан муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, баш бухгалтерларның һәм бухгалтерларның (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Югары Ослан муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләренә һәм белгечләренә, баш бухгалтерларга һәм бухгалтерларга (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм аның шартлары турында» Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 23.04.2019 ел №394 карары белән расланган «Авыл

җирлекләренең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ һәм «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ, «Югары Ослан муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм аның шартлары турындагы Нигезләмәнең 3 нче пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Авыл җирлекләренең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ һәм «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ, Югары Ослан муниципаль районы Мәдәният бүлеге» МКУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлеге өчен | Муниципаль казна учреждениесенең структур бүлекчәсе булган үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлеге өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 40700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 38100 | |
| Структур бүлекчә җитәкчесе (баш хисапчы) | | 38100 |
| Бүлек башлыгы | 33600 | 33600 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 30600 | 30600 |
| Хисапчы | 29000 | 29000 |

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш».

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе А.А.Ахметшин

Әзерләде һәм бастырды
Е.Е. Колесова 4 нөсхәдә.